Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

11 март 2013 ел №286

Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә кую, административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы урындагы затларның исемлеген билгеләүче вәкаләтле орган турында

Үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән:
23 август, 19 декабрь 2013 ел,30 март, 27 декабрь 2017 ел.

“Татарстан Республикасы җирле үзидарә муниципаль берәмлекләренә административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы урындагы затларның исемлеген билгеләүче Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләте бирелү” турындагы 2010 елның 30 июлендәге № 60–ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы карар бирә:

Үзгәрешләр турында мәгълүмат:
*2017 елның 27 декабрендә кабул ителгән 219 нчы санлы карарның 1 нче пунктына үзгәрешләр кертелгән – Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 27 декабрендә кабул ителгән 219 нчы карары*

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетын, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турындагы Кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, предприятие һәм башка оешмаларның алтакталарында күрсәтелгән мәгълүмат буенча Татарстан Республикасы телләре турындагы закон бозуга мөнәсәбәтле рәвештә), 2.4–2.8, 2.12.–2.14, 3.2.–3.8., 3.10., 3.11., 3.14.–3.16.,4.4.,5.1.,5.2.,5.6 нчы (муниципаль берәмлек территориясендә алып барыла торган товар ташуларга мөнәсәбәтле рәвештә) маддәләрендә каралганча, Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтен гамәлгә кую, административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы урындагы затларның исемлеген билгеләүче вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына административ хокук бозулар хакында беркетмә төзергә хокуклы урындагы затларның исемлеген билгеләргә.

3.Әлеге карарны рәсми рәвештә “Знамя труда”, “Альметьевский вестник” газеталарында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы Советының закон, хокук саклау, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Р.И. Шәфигуллин) йөкләргә.

Әлмәт муниципаль районы башлыгы М.Х.Салихов